| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның 18 декабре Балык Бистәсе штп. № 502

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясен тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, әйләнә-тирә мохитне саклау, территорияләрне планлаштыру өчен шартлар тудыру, физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 маддәсендәге 1 пунктына, 30, 31, 32 маддәләренә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүгә керешергә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 24.12.2018 ел №149 карары белән расланган 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиянең яңа составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. 2 нче кушымта нигезендә шәһәр төзелешен зоналаштыру этапларын билгеләргә.

4. Расларга:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү тәртибен һәм срокларын;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш  алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча кызыксынган затларның тәкъдимнәрен «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару  кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау комиссиясенә җибәрү тәртибен.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы  Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең  түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Балык Бистәсе штп., Ленин ур., 48А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне  үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче М.В. Мәгыйзов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балык Бистәсе шәһәр
җирлеге Башкарма комитетының
2023 елның 18 декабрендәге
502 номерлы карарына
кушымта №1

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия составы**

Мәгыйзов Марс Венер улы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;

Вафин Фәрит Мансур улы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары (килешенү буенча);

Старикова Мария Александровна – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия сәркатибе;

Комиссия әгъзалары:

Ризаев Дамир Наил улы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары (килешенү буенча);

Хәмидуллин Ирек Мәсгут улы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы (килешенү буенча);

Петрова Эльвина Замир кызы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешенү буенча);

Токранов Вячеслав Иванович – Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенең Балык Бистәсе бүлеге башлыгы (килешенү буенча);

Сәйфуллина Лилия Җәүдәт кызы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе урынбасары (килешенү буенча);

Сөләйманов Динар Шамил улы – “Балык Бистәсе район дәүләт ветеринария берләшмәсе” ДБУ башлыгы (килешенү буенча).

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балык Бистәсе шәһәр
җирлеге Башкарма комитетының
2023 елның 18 декабрендәге
502 номерлы карарына
кушымта №2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләгәндә шәһәр төзелеше зоналаштыру этаплары**

1 нче этап – территориянең хәзерге торышын анализлау, җирдән файдалануны һәм территориядән файдалануның аерым шартлары булган зоналарда (саклана торган, санитар-саклау зоналары, мәдәни мирас объектлары саклана торган зоналар) билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен, җирлекне үстерү программалары исәпкә алып башлангыч мәгълүмат җыю.

2 нче этап – җирлек территориясендә республика һәм федераль әһәмияттәге гамәлдәге һәм планлаштырыла торган объектларны анализлау;

3 нче этап – территориаль зоналарның чикләрен формалаштыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балык Бистәсе шәһәр
җирлеге Башкарма комитетының
2023 елның 18 декабрендәге
502 номерлы карарына
кушымта №3

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү буенча эшләрне башкару тәртибе һәм сроклары**

| № п/п | Кагыйдәләр проектын әзерләү буенча эшләрне үткәрү тәртибе | Эшләрне үткәрү вакыты (сроклары) | Башкаручы, җаваплы зат |
|---|---|---|---|
| 1 | «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү турында карар кабул итү | 2023 елның декабре | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты |
| 2 | «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакындагы карарны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) | Кабул ителгән вакыттан алып 10 көн эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты |
| 3 | Физик һәм юридик затлардан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча тәкъдимнәр кабул итү | Карар басылып чыкканнан соң бер ай эчендә | Комиссия |
| 4 | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча эшләр үткәрү | Подряд шартнамәсе нигезендә | Шартнамә буенча подрядчы |
| 5 | Россия Федерациясе Балык Бистәсе муниципаль районы җирлегенең техник регламентларына, территориаль планлаштыру документларына туры килү-килмәү проектын тикшерүне, беркетмәләр һәм бәяләмәләр әзерләүне тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе | 7 көн эчендә | Комиссия |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрү | | |
| 6 | Проектны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башлыгына җибәрү | 5 көн эчендә | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты |
| 7 | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында карар кабул итү | Алганнан соң 10 көн эчендә | Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башлыгы |
| 8 | Гавами тыңлауларны үткәрү турында карарны бастырып чыгару | Кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә | Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башлыгы |
| 9 | «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегенең Бирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект материаллары экспозициясен ачу | Карар кабул ителгәннән соң 2 көн эчендә | Комиссия |
| 10 | «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү | Халык тыңлауларын билгеләү турында Карар кабул ителгән көннән алып бер айдан артык түгел | Комиссия |
| 11 | Гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләүне тәэмин итү, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырып чыгару | Гавами тыңлаулар уздырганнан соң 10 көн эчендә | Комиссия |
| 12 | ТР Балык Бистәсе районы прокуратурасына коррупциягә каршы экспертизага Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советына «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны җибәрү | 30 көн эчендә | Комиссия |
| 12 | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советына «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны җибәрү | 12 нче этап тәмамланганнан соң 5 көн эчендә ТР Балык Бистәсе районы прокуратурасыннан уңай бәяләмә алганда | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13 | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы утырышында раслау | Район Советының чираттагы утырышында | Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы |
| 14 | «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару | Раслanганнан соң 10 көн эчендә | Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балык Бистәсе шәһәр
җирлеге Башкарма комитетының
2023 елның 18 декабрендәге
502 номерлы карарына
кушымта №4

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү буенча мөрәҗәгатьләрне карау комиссиясенә җибәрү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында хәбәр бастырылганнан алып билгеләнгән вакыт эчендә кызыксынган затлар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү комиссиясенә үз тәкъдимнәрен юлларга хокуклы.

2. Тәкъдимнәр шәхсән бирелә яки түбәндәге адрес буенча почта аша җибәрелә: 422650, РТ, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Ленин ур., 48 йорт, электрон почта адресы: Rs.Rs@tatar.ru «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе» шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектларын әзерләү комиссиясенә» тамгасын куеп.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектка тәкъдимнәр кире адресын һәм тәкъдимнәр әзерләү датасын күрсәтеп, аларны бәян иткән гражданның ФИО сы яки имзасы белән булырга тиеш.

4. Тәкъдимнәрдә теләсә нинди материал (кәгазьдә дә, электрон йөрткечләрдә дә) булырга мөмкин. Җибәрелгән материаллар кире кайтарылмый.

5. Билгеләнгән вакыт узганнан соң комиссиягә кергән тәкъдимнәр, имзаланмаган тәкъдимнәр, шулай ук Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләүгә катнашы булмаган тәкъдимнәр комиссия тарафыннан каралмый.